# СЕБЕРКЕ

(БӘХЕТСЕЗ ГАИЛӘЛӘР, ГЫЙБРӘТЛЕ ЯЗМЫШЛАР ТУРЫНДАГЫ ГАЗЕТА)

№ 14 (569)
10-16 АПРЕЛЬ
2023 ел

16+

Газетаның индексы - П 2496



*Адәм гомере - гөрләвек гомере,*
*Ул охшаган кыска юлга.*
*Исемнәрен Күктә теркәлә дә,*
*Җирдә языла тик комга.*
**Заһид МӘХМҮДИ.**



АЙГА
ДҮРТ ТАПКЫР
ЧЫГА

**Бу санда укыгыз:**



## Рәнҗешме, тәкъдирме?

*6-8 нче битләр*

## Йөрәккә әмер биреп буламы?





...Зар-интизар булып әтигә күңелемне бушатканда, ул миңа гел бер сүзне кабатлады: “Кызым, үзең ярату хисен кичермичә, син мине мәңге аңлый алмаячаксың. Әллә мин сезнең газаплануларны күрми, сизми дип беләсеңме? Ялгышасың! Барысын да беләм мин, тик йөрәккә әмер биреп булмый икән”...

*9 нчы бит*



## Бозык хатыннар сихере

*21 нче бит*

podpiska.pochta.ru

## КӨН КАДАГЫНА

# Җиңүнең 78 еллыгына – Ветераннарга акчалата бүләк



Татарстанда 295 ветеран Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 78 еллыгы хөрмәтенә бер тапкыр бирелә торган түләү алачак. Социаль фондның республика буенча бүлеге инде апрель аенда ук 248 Бөек Ватан сугышы ветеранына һәм 47 инвалидка 10ар мең сум күләмендә акча күчерәчәк. Бу акчаны пенсия белән бергә бирү күздә тотыла.

Россия Социаль фондының Татарстан буенча бүлеге идарәчесе Эдуард Вафин әйтүенчә, Социаль фонд 2019 елдан бирле ветераннарга Җиңү көненә бүләк бирү мәсьәләсен хәл итеп килә. Шул рәвешле якташларыбызның батырлыклары һәм фидакарь хезмәтләре хөрмәтләнелә.

Җиңүнең 78 еллыгына акчалата бүләк алу өчен гариза тапшырырга кирәкми. Ул Социаль фонд бүлеге мәгълүматлары нигезендә бирелә. Ягъни ветераннарга, аларның якыннары яки вәкилләренә Социаль фонд бүлегенең клиент хезмәтләренә мөрәҗәгать итәргә кирәкми, дигән сүз.

# Ана капиталыннан ай саен акча алырга мөмкин




Аз керемле гаиләләр ана капиталыннан ай саен акча алып торырга мөмкин. Бер айда яшәү минимумына тигез күләмдә акча бирелә. Балага өч яше тулганчы, шул рәвешле акча алырга була.

Моның өчен гариза язып тапшырырга кирәк. Россия Пенсия фонды бүлегенең клиентлар хезмәтенә барып, яки Пенсия фонды сайтында электрон рәвештә, яисә Дәүләт хезмәтләре порталы аша хәл итеlә бу.

Балага 3 яшь тулганчы теләсә кайсы вакытта түләүне алу өчен мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Башта ул бер елга билгеләнә. Гаилә алга таба да ана капиталын шулай тотарга ниятләсә, янә гариза тапшырырга кирәк булачак.

Айлык түләү билгеләү өчен бала туганнан соң алты ай эчендә мөрәҗәгать ителгән очракта түләү бала туган көннән билгеләнә. Алты айдан мөрәҗәгать иткән очракта, түләү мөрәҗәгать иткән көннән билгеләнә.

Россия Пенсия фонды мөрәҗәгать итүченең һәм аның гаиләсе әгъзаларының керемнәре турында мәгълүматларны мөстәкыйль җыя. Гаиләләрнең күпчелегенә керем турында белешмәләр тапшырырга кирәкми. Баланың әтисе яки әнисе хәрби, коткаручы, полиция хезмәткәре яисә башка көч ведомствосы хезмәткәре булып торганда, шулай ук гаиләдә кемдер стипендия, грант, уку йортыннан башка түләүләр алганда гына керемнәрне расларга кирәк булачак.

# Бакчачылык җәмгыятендә машина юган һәм ремонтлаган өчен штрафка тартачаклар



Бакчачылык җәмгыяте территориясендә машина юган һәм ремонтлаган өчен штраф сала башлаячаклар, аның күләме 3-5 мең сум тәшкил итә. Әгәр туфракның пычрануы ачыкланса, штраф төрле шартларга бәйле рәвештә 10 мең сумга кадәр артачак.

Елга буенда су саклау зонасының озынлыгы сулыкның озынлыгына бәйле. Озынлыгы 10 километрдан артмаган кечкенә елгаларның яр буена - 50 метр, 50 километрдан артыграк булган сулыкларга машина белән 100 метрдан да якынрак килергә ярамый, ә диңгез су саклау зонасы ярты километр тәшкил итә.

Әгәр каты өслекле - асфальт яки вак таш җәелгән юл хакында сүз бара икән, бу очракта елга яки күлгә рөхсәт ителгәннән якынрак килергә мөмкин. Бу таләпне бозган өчен штраф күләме физик затлар өчен - 5 мең, оешмалар өчен 400 мең сумга кадәр тәшкил итә.

Агач-куаклар утыртылган участокка машина куйган өчен дә җәза каралган. Мәскәү өлкәсе Административ хокук бозулар кодексы нигезендә, физик затлар моның өчен - 5 мең, оешмалар 100 мең сумга кадәр штрафка тартылачак.

Махсус рөхсәттән башка милли парк, заказник, тыюлык һәм ботаника бакчалары буйлап машинада барган өчен физик затларны - 3-4 мең, юридик затларны 500 мең сумга кадәр штраф көтә, диелә бу хәбәрдә.

*(“Татар-информ”)*

podpiska.pochta.ru

*Кино түгел, чынбарлык!*

# ФАТИРЫҢ ДА КАЛДЫРМАГАЧ, НИГӘ КИРӘК УЛ БЕЗГӘ?



Гамәлләрең фәкать саваплы гына түгел, бәлки игелекле дә булырга тиешле ай шул ул Рамазан. Изге Рамазан! Гайбәт сөйләмичә, ямьсезгә карамыйча, нәфесне узындырмыйча яшәүдән ләззәт алып яшәп кала мөэмин мөселман өммәте уразa аенда. Уразасын да кылган гөнаһларыннан арыну, тазарыну, пакьләнү өчен дип тота. Гамәлләре кабул булсын аларның! Югыйсә шулай матур итеп яшәү елның һәр фасылы өчен дә хас булырга тиештер ул.

Савап, игелек турында болай да, Рамазан ае кермәгән булса да, язарга ниятем бар иде. Чөнки әҗерсез, рәхмәтсез яхшылык кылганнары өчен битәр, әр сүзләре ишетелгәләп куя.

Әҗер савап, вәҗеп савап дигәннәре ни-нәрсә соң ул? Риясыз эшләнгән яхшылык - чын яхшылык шул була дип өйрәттеләр безне үскәндә. Халык мәкале дә гел шуны искәртеп торды: яхшылык эшлә дә, суга сал - халык күрер, халык күрмәсә, балык күрер! Кодрәтеннән килгән берәүнең икенче берәүгә ярдәме беренчесенә җиңеллек китерсә, икенчесенә әҗер савап китерүе дә хак.

Җавапка һичшиксез әҗер көздә тотылган гамәл ничек дип атала икән? Күрше кызы Карина музыкага укыды. Әти-әнисе аны, һичшиксез, танылган пианист итеп күрделәр. Кыз сәләтле булгандыр. Чөнки һәртөрле конкурсларда бәләкәйдән катнаша башлады. Әмма ул шук бала музыканы, бигрәк тә пианинода уйнауны бер җәза, хәтта ки каза кебек кабул итә иде бугай. Һәрхәлдә дәресләрдән азат булу өчен ул такта белән сугып кулын сындырып та карады. Кыш көне юеш җәймәгә төренеп балконга чыгып та торды.

Әти белән әни кызларының бу “бәхетсезлекләренә” бик көенәләр иде. Көенмәслекме? Дәрәҗәле генә урыннар биләүче бу икәү тормыш мәгънәсе, яшәү максаты итеп, кызларының киләчәк данлы балкышын гына күрәләр иде.

Ничек итсәләр иттеләр, Каринага мәшһүр остаз таптылар. Бу әбинең шәкертләре танылган музыкантлар иде. Хәзер әби Карина белән генә шөгыльләнәчәк. Тик профессор әби шактый олы яшьтә - ярдәмгә мохтаҗ. Күршеләрем әбине кул очында гына йөртергә керештеләр - якшәмбе саен кунакка алалар. Өенә барып йөриләр. Өен җыештыралар, азык-төлеген илтәләр. Табибка-нигә машинада гына алып баралар (элегрәк бит әле бу - машиналар аз чагында). Мин бу ата-ананың бала хакына кылган игелекләрен сөенеп күзәтеп йөрим: әбинең кызыксыз тормышын ямьләделәр ләбаса!

Каринаның холкы үзгәрмәде. Ул һаман шулай шаян, шук! Профессорның сабакларын өйрәнгәндәй итә дә, конкурс көне килеп җиткәндә генә берәр шуклык эшләп, сафтан чыга. Ата-ана биреште. Кыз ташлады музыканы. Әмма әбине карау тукталмады. Хикмәт музыкада булмаган икән бит. Музыкалы уйнау нечкә күңелле, талантлар хакына дөньясын онытырга әзер әбинең йөрәгеген яулау булган икән соңгы максат. Йөрәк кирәк! Чөнки әбинең әйбәт фатиры бар, ә менә варислары юк. Ул заманда әле фатирларны мирас итеп язып калдырулар, бүләк итүләр юк иде. Фатирга пропискага кереп урнашасың да, фатир үзеннән-үзе шунда яшәп торучы кешегә күчеп кала.

Инде Каринаны әбигә пропискага кертәбез дигәндә генә, профессорның ерак туганы пәйда булды. Табигый ки, әби варис итеп туганын сайлады. Менә шушы хакыйкать ачылгач, әбинең кунакка килүләре тукталды, хәлен белеп йөрүләргә дә чик куелды. Алай гына да түгел, “рәхмәтсез” әбине сүз белән каһәрләүләр башланды. Берничә елга сузылган “игелек акциясе” әнә шулай күңелсез тәмамланды. Әле пионер галстугын да салмаган кызыкай: “Фатирың да калдырмагач, нигә кирәк ул безгә?” - дип өйдә сөйләнгән сүзләрне безгә дә бушатып чыгып китте...

Ә Каринадан менә дигән бизнесмен килеп чыкты. Чит илдән товар ташый-ташый кибетләр ачып җибәрде. Рухланып эшли. Бер фатирын сатып икенчесенә күченгәндә пианиносын да подъездда калдырып китте. Бик исәп-хисап рәтен белә торган кыз булып чыкты ул.

**Исемем редакция өчен генә.**

## *ХӘДИС*

*Әгәр сине яхшы эшләрең шатландырса һәм бозык эшләрең кайгыга салса, димәк, син мөэмин икәнсең.*

podpiska.pochta.ru

# Рамазан уразасына бәйле кайбер сораулар



***Белә торып уразаңны бозсаң нишләргә?***

Рамазан уразасын белә торып бозган кеше шул гөнаһысы өчен ике ай тоташ ураза тотарга тиешле була (кәффарәт).

Әгәр кеше хасталык сәбәпле ике ай тотарга көче җитмәсә, алтмыш мескенне ашатырга тиешле була.

***Ураза вакытында, көндез йоклаганда төшләнеп госелең бозылса ураза ачыламы?***

Ураза бозылмый. Госел коенып уразаны дәвам итәсең.

***Рамазан аеның казага калынган көннәрен кыш вакытында тотсаң ярыймы?***

Казага калган уразаларны Корбан вә Ураза бәйрәмнәреннән башка нинди көнне тотсаң да дөрес санала. Җәй көннәрендә ураза тотарга авыр булса, кыш көннәрендә тоту мөмкин.

***Хасталык, яки башка кирәклек туып, ураза вакытында борын эченә дару салу ярыймы?***

Борын эченә салырга да, тамакка дару чәчрәтергә дә ярамый. Дару тамактан ашказанына китеп уразаны бозар.

## Май аена намаз вакытлары

| | Иртәнге намаз | Кояш чыга | Өйлә | Икенде | Ахшам | Ястү |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2:31 | 4:01 | 12:00 | 16:52 | 19:21 | 21:45 |
| 2 | 2:29 | 3:59 | 12:00 | 16:53 | 19:23 | 21:49 |
| 3 | 2:27 | 3:57 | 12:00 | 16:55 | 19:25 | 21:54 |
| 4 | 2:25 | 3:55 | 12:00 | 16:56 | 19:27 | 21:58 |
| 5 | 2:23 | 3:53 | 12:00 | 16:57 | 19:29 | 20:59 |
| 6 | 2:20 | 3:50 | 12:00 | 16:58 | 19:31 | 21:01 |
| 7 | 2:18 | 3:48 | 12:00 | 16:59 | 19:33 | 21:03 |
| 8 | 2:16 | 3:46 | 12:00 | 17:01 | 19:35 | 21:05 |
| 9 | 2:14 | 3:44 | 12:00 | 17:02 | 19:37 | 21:07 |
| 10 | 2:12 | 3:42 | 12:00 | 17:03 | 19:39 | 21:09 |
| 11 | 2:10 | 3:40 | 12:00 | 17:04 | 19:41 | 21:11 |
| 12 | 2:08 | 3:38 | 12:00 | 17:05 | 19:43 | 21:13 |
| 13 | 2:06 | 3:36 | 12:00 | 17:06 | 19:45 | 21:15 |
| 14 | 2:04 | 3:34 | 12:00 | 17:07 | 19:47 | 21:17 |
| 15 | 2:03 | 3:33 | 12:00 | 17:08 | 19:48 | 21:18 |
| 16 | 2:01 | 3:31 | 12:00 | 17:09 | 19:50 | 21:20 |
| 17 | 1:59 | 3:29 | 12:00 | 17:10 | 19:52 | 21:22 |
| 18 | 1:57 | 3:27 | 12:00 | 17:11 | 19:54 | 21:24 |
| 19 | 1:55 | 3:25 | 12:00 | 17:12 | 19:56 | 21:26 |
| 20 | 1:54 | 3:24 | 12:00 | 17:13 | 19:57 | 21:27 |
| 21 | 1:52 | 3:22 | 12:00 | 17:14 | 19:59 | 21:29 |
| 22 | 1:51 | 3:21 | 12:00 | 17:15 | 20:01 | 21:31 |
| 23 | 1:49 | 3:19 | 12:00 | 17:16 | 20:03 | 21:33 |
| 24 | 1:48 | 3:18 | 12:00 | 17:17 | 20:04 | 21:34 |
| 25 | 1:46 | 3:16 | 12:00 | 17:18 | 20:06 | 21:36 |
| 26 | 1:45 | 3:15 | 12:00 | 17:19 | 20:07 | 21:37 |
| 27 | 1:43 | 3:13 | 12:00 | 17:20 | 20:09 | 21:39 |
| 28 | 1:42 | 3:12 | 12:00 | 17:21 | 20:10 | 21:40 |
| 29 | 1:41 | 3:11 | 12:00 | 17:22 | 20:12 | 21:42 |
| 30 | 1:40 | 3:10 | 12:00 | 17:22 | 20:13 | 21:43 |
| 31 | 1:38 | 3:08 | 12:00 | 17:23 | 20:15 | 21:45 |

***Кеше сау-сәләмәт булып, калган уразалары өчен фидия сәдакасы гына бирсә ярамыймы?***

Ярамый, чөнки сау-сәләмәт, ураза тотардай булган кеше калган уразаларын каза кылырга тиеш. Хасталанган, йә картайган, киләчәктә берничек тә ураза тотарга мөмкинчелеге булмаганы билгеле кешеләргә генә фидия бирү ярый.

***Намаз укымыйча ураза тоту дөресме?***

Намаз уку, Коръәндә язылган, мөселманнарга фарыз иттереп билгеләнгән динебезнең бер гамәледер. Белә торып намаз укымау зур гөнаһтыр. Ураза тоту да Аллаһның кушканы. Аллаһның кушкан нәрсәләренең берсен эшләп икенчесен калдыру - кешенең Аллаһка ышануының зәгыйфь икәнлеген күрсәтә. Кем дә булса, намаз укымыйча ураза тота икән, тотсын. Аның ураза тотуы, тотмавыннан күпкә хәерлерәк.

***Рамазан аенда юлга чыгып уразаны казага калдыру дөресме?***

Нindидер бер сәбәп белән үзенең өеннән 100 чакрым ераклыкка, яки тагы да ераграк җиргә юлга чыккач, авылның, я шәһәрнең чигеннән узу белән - кеше мөсафир санала.

Мөсафирга Рамазан аендагы фарыз уразасын казага калдырырга, мөсафирлар өчен динебезнең башка җиңеллекләрен кулланырга мөмкин. Бу динебез буенча каралган җиңеллекләр мөсафирның киткән юлыннан кире кайту вакыты билгеләнгән кадәр дәвам итә. Кайту вакыты билгеләнмичә берничә ай узса да - кеше мөсафир хөкемендә саналыр.

Мөсафир барачак җирендә унбиш көннән артык калырга ниятләсә, шул җиргә барып җитүе белән мөсафирлыктан чыга. Уразасын да, намазларын да тулысынча үтәргә тиешле була.

***Хәез вакытында ураза тотарга ярамый. Нинди гыйбадәтләр башкарырга була соң?***

Хәез - хатын-кыздарда һәр ай була торган табигый күренеш. Бу чорда хатын-кыз чиста булып саналмый. Шуңа күрә дә гүзәл затлар бу вакытта ураза тотмый. Хәез вакытында зекерләр укырга, дога кылырга, яттан белгән аятьләрне укырга һәм кабатларга, тәфсирләр, дини китаплардан гыйлем алырга ярый. Хәез тәмамлангач, хатын-кыз госел ала, ягъни тулысынча юына.



podpiska.pochta.ru

***Уразалы килеш спорт белән шөгыльләнү уразаны бозамы?***

Уразаны боза торган гамәлләрдән кала башка гамәлләр белән шөгыльләнү уразаны бозмас. Спорт белән шөгыльләнү, иң элек, авырлык китерергә тиеш түгел. Ураза авырлык булып тоелмасын өчен, организмны талчыктыра торган авыр хезмәтләрне вакытлыча кичектереп тору киңәш ителә.

***Авыз ачканда хөрмә ашыйбыз. Моның берәр хикмәте бармы? Башка җиләк-җимеш кулланырга ярамыймы?***

Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) авыз ачканда иң беренче булып хөрмә кабып куйган. Хөрмә белән авыз ачу - сөннәт гамәл. Бу җимеш бик файдалы. Шуңа күрә, көн дәвамында ач торганнан соң, аны ашап кую организм өчен файдага булыр.

***Йөкле хатыннар ураза тотарга тиешме?***

Үзләренең хәлләренә карап, табиблар рөхсәте белән ураза тота алалар. Әгәр ураза тоту саулыкларына, йә туачак балага зарарлы булса, ураза тотмаслар. Рамазан ае беткәннән соң, мөмкинчелек булу белән калдырган көннәрен ураза тотарлар. Бала ашатучы хатын ураза тотып, сөте бетүдән курыкса, шулай ук уразасын каза кылыр.

*Белү зыян итмәс*

# Хөрмә - җәннәт җимеше



*Хөрмә бик файдалы җимеш. Кеше 10 айдан артык хөрмә (финик) белән генә тукланып тора ала. Бу җимештә организмга кирәкле бөтен элементлар да бар.*

*Хөрмә җимеше яраткан кешеләрнең тешләре һәм казналыклары нык була.*

*Хөрмәне, башка киптерелгән җимешләр кебек, күкерт кислотасы белән эшкәртмиләр. Шуңа аны курыкмыйча ашый аласыз.*

*Көндәлек рационга хөрмә җимеше кертән кеше беркайчан күңел төшенкелегенә бирелми.*

*Хөрмә организмнан токсиннар һәм шлакларны чыгара, симерүгә каршы нәтиҗәле чара булып тора. Ул иммунитетны ныгыта, хәтерне яхшырта.*

*Бу җимеш составында күкрәк сөтен арттыручы окситоцин матдәсе бар. Бала имезүче аналар моны истә тотарга тиеш.*

*БЕЛГЕЧЛӘР ФИКЕРЕ*

## Бәрәңгене кайчан утыртасы?!

Татарстанның районнарында кайберәүләр бәрәңге утыртырга өлгергән инде. Икенче "икмәк"не утыртыр вакыт та җиттемени?

Галим, биология фәннәре кандидаты Габделхәй Сәмигуллин бәрәңге утырту өчен апрель ахырын сайлаган.

"Быел яз ике атнага иртәрәк килде. Кызганыч, яңгыр гына юк: туфрак коп-коры. Мин бәрәңгене ай ахырында утыртырга ниятләдем, - ди ул. - Бәрәңге бүлбеләренең шытучанлыгы яхшы, инде 10-12 көннән үк шытым бирергә мөмкиннәр. Әгәр кинәт суытып җибәрсә, аларны күмеп чыгарга, черемә белән капларга өлгерәм".

Экспертыбыз орлык бәрәңгесен әзерләү серләре белән дә уртаклашты: шыттыру өчен, башта ул аларны 2-3 көн яктыда - кояш астында тота икән, соңыннан җылы урынга - теплицага күчерә. Алдан ук туклландыргыч сыеклык әзерли: һәр чокырга бер уч гади көл, шуннан әз генә күбрәк черемә, һәм, корткычлардан саклау өчен, башлы суганның 4-5 кабыгын сала.

Фермер Минталип Миңнеханов исә бәрәңгене 8-9 майда утырта.

"Инде 23 ел дәвамында шул график - басуларга май аенда чыгабыз, - ди ул. - Аннан да иртә чыгуның файдасы юк, кырау сукмас, дип гарантия биреп булмый, туфрак та әле әзер түгел: кирәгенчә җылынмаган, житешмәгән. Үз тәҗрибәмнән чыгып шуны әйтәм: иң яхшысы - ашыкмый тору. Иртәрәк утырту вакыт ягыннан отыш бирми, салкын туфракта бүлбеләр барыбер үсми генә ятачак".

### ЛОТЕРЕЯ уенына санаулы көннәр калып бара!

**Хөрмәтле газета укучылар!**



Редакциябездә лотереяда уйнатылачак затлы бүләкләр тулысы белән тупланды. Берникадәр кичектерүләрдән соң, ниһаять, лотерея уйнатылыр дулкынландыргыч мизгел дә килеп җитте. Газетабызның киләсе санында лотереяда бәхет елмайган җиңүчеләр исемнәре белән таныша алачаксыз. Бәлки нәкъ менә сез җиңүчеләр рәтендә булырсыз.

Барыгызга да уңышлар теләп калабыз!



podpiska.pochta.ru

# Акча дип азынып, хатын дип тузынып

Район үзәге авыл җире кебек бит ул. Анда серләр озак сакланмый, кешеләр бер-берсен яхшы белә. Әнәс абыйның кыланмышлары да гаиләләрен белгән һәркемгә мәгълүм.

Хатыны Әлфия апа өстеннән бик йөри ул. Башта администрациядә эшләүче, иреннән аерылып кайткан бер хатын белән типтерде, анысын ташлагач, бер тол кибетчегә барып ябышты. Сүз дә юк, теге хатыннар яннарыннан куса, ир йөрмәс иде. Менә шулай алдалый-юмалый белә инде Әнәс абый. Җитмәсә уч тулы акчасы бар.

Хатыны Әлфия апаны барысы да бик кызгана. Сабыр холыклы, тыныч ханым ул. Берәүгә дә начарлыгы тигәне юк. Иренең кыланмышларын белә, тик нишләсен соң - азгын ирне тыеп тора алмый. Бишенче дистәне түгәрәкләп маташканда, ирдән аерылып кеше көлдерәсе дә килми. Ярый ла иренең өстеннән йөрүенә генә түзеп яшисе булса, бер хәер. Ире кече улын үзенеке итеп танымый бит! Әлфия апаны: “Чит ир белән йөреп тапкансың син аны”, - дип битәрли ди. Бу хакта гаилә дуслары әйтте.

Төпчекләре Илсур бер дә үзләренә охшамаган. Хатыйп абый да, Әлфия апа кара чәчле, каракучкыл тәнлеләр. Олы уллары Илнар да шундый: чем кара кашлы-күзле. Ә Илсур - сары. Әнәс абыйның ике энесе дә җирән чәчлеләр инде, югыйсә. Юк, көнләшүдән күзе сукырайган ул Әнәс абыйның. Үзе хатыны өстеннән йөргәч, Әлфия ападан да шикләнә инде. Әлфия апа чит ир белән йөрү түгел, хәтта күршедәге агайлар белән дә күзен җирдән аермыйча гына исәнләшә. Тәртип белүче, акыллы хатын. Шушы ялага ничек түзәдер инде, белмим. Адәм көлкесе бит!

Әле ярар шикләнеп, көнләшеп кенә калса, Әнәс абый улларын аера бит, газиз балаларын аера. Илнарны сөйләшеп, акча төртеп университетта укытты. Зур урыннарда утыручы танышлары аша менә дигән эшкә урнаштырды. Ә Илсурга ярдәм итмәгән, күрәсең, училище гына бетерде анысы. Сер бирәсе килмәгәндер инде, иптәшләре арасында: “Югары белем нигә ул, үзем теләгәнгә укыдым мин. Хәзер эретеп ябыштыручылар нәчәлникләрдән күбрәк акча эшли”, - дип сөйләгән.

Хәзер инде укып бетереп, үз гаиләләрен коргач та, Әнәс абый Илнарга гына ярдәм итеп тора дип беләбез. Илсур гап-гади бер бүлмәле фатирда яши. Ә бертуган абыйсы Илнар таш пулатта яши, үзе дә, хатыны да кыйммәтле иномаркаларда гына йөриләр. Анысы, әтисе сүзен куәтләптер инде, Илсурны якын итми.

Гаҗәп инде менә, башка сыймаслык хәл бу. Акча дип азынып, хатыннар дип тузынып яшәгән ата кеше үзенең улларын аерып карый. Бу хәлләргә Әлфия апа ничекләр түзәдер инде. Әле безгә - гомумән чит кешеләргә дә - бик сәер хәл бу.

(Исемнәр үзгәртелде).
**Исемем редакция өчен генә.**

*Намусны җуймыйча яшик!*



# Рәнҗешме, тәкъдирме?

Илшат Лилия белән бик күптәннән очрашып йөрсә дә, кызы белән әниләрен таныштырганы юк иде әле. Алар очраклы гына даруханәдә очраштылар. Гөлсинә булачак киленнен баштан-аяк күзәтеп чыкты да, тутырып улына карап куйды. Илшатның йөрәге шул чакта ук жу итеп куйды. Әнисеннән рәтле сүз ишетмәячәген чамалады ул. Лилиягә сиздермәс өчен елмаерга һәм тизрәк даруханәдән чыгып китәргә тырышты.

- Нәсел ваклап, тапкансың кыз. Чеби кадәр хатыннан ни килер дип беләсең, - диде улы өйгә кайтып керүгә Гөлсинә. Бик күп кызларны үрнәк итеп куйды, кечкенә генә гәүдәле, мөлаем авыл кызын тәмам бетереп атты.
- Бер күрүдә ошатмадым. Юк, кабул итә дә алмыйм, безнең нәселгә төс түгел, - дип сүзен тәмамлады.

Илшат чыгып китте, башка бу темага әйләнеп кайтучы булмады. Бу вакытта яшьләр укуларын тәмамлап кайткан, эшкә урнашканнар иде инде. Төгәл туй көне билгеле булмаса да, бергә булу хыяллары көчле, бер җеп булып бәйләнгәннәр, уй-максатлары уртак. Бер-берсеннән башка киләчәкне күзаллый да алмыйлар. Көчле мәхәббәт булганда, каршылыкларга да исләре китмәде.

* * *

Уйлап карасаң, Лилиянең тормышы бик мәшәкатьле, борчулы һәм сагышлы булды. Күккә карарга түгел, аяк астына карап атларга да хәле булмаган, күнеле үсмәгән көннәре дә бар. Күңел яралары гел сиздереп, сулыксулык килеп тора.

podpiska.pochta.ru

Тормыш иптәше инде вафат. Кайнанасы белән аралар өзелгән. Аның каравы, янәшәсендә баһадирдай уллары бар. Нәсел дә вакланмаган, йөзләренә кызыллык та килмәгән. Тик бу хакта сөйләргә дә, кемгәдер нидер дәлилләргә дә соң инде. Буласы - булган, ишетәсен - ишеткән.

- Табигатьтән көч алам. Күңелгә тия торган вакыйгалардан рухым төшә, көчем бетә. Кешеләрнең явызлыгыннан тыным кысыла. Хаксыз икәнлекләрен белә торып пычрак чәчү нигә кирәк, - дип хәзер дә Лилия еш искә ала.

Күпләрнең язмышына ялгызлык язылмаган. Сыңар канат белән очарга азаплануны күпләр аңламый. Чат саен кырыслыклар очрый. Кайчан, ничек, ни сәбәпле ялгыз каласыңны белеп булмый. Парлы чакта бик рәхәт тә бит. Каргышмы бу, рәнҗешме? Яшәргә нәрсә комачаулый. Әти-әни фатыйхасы җитеп бетмиме? Бу сорауларга бер Лилия генә җавап эзләмидер.

* * *

Күп очракта язмышларны кеше куллары, акылы белән яза, диләр. Лилия моның белән килешми. Адәм баласы тәкъдирдә язылган сукмак буйлап бара түгелме соң? Еш кына башкалар да йогынты ясый. Илшатның беркайчан кешегә начарлык эшләгәне, авыр сүз әйткәне булмады. Лилия дә кеше рәнҗеткәнен хәтерләми. Хатын белән әнисе арасында озак бәргәләнде Илшат. Берсенә дә авыр сүз әйтә алмады. Барысын да йөрәгенә җыйды. Ахыр чиктә сабырлыгы бетте бугай. Авыруларга бирешә башлады. Аз сүзлегә әйләнде.

Илшат - районның бер зур оешмасында хисапчы булып эшләде. Җаваплылык, төгәллек, акыл эшчәнлеге таләп иткән хезмәтеннән арган-талчыккан чакларында гаиләсе янында ял итәргә, җылылык табарга теләде.

Лилия - китапханәче. Югары белемле укытучы булса да, мәктәпкә барырга теләмәде. Бергә чакларда бик бәхетле иде гаилә. Лилия тулышкан чакларында иренә зарланса да, Илшат беркайчан урамдагыны өенә алып кайтмады.

Йорт та салып чыктылар. Ике уллары туды. Лилия кыз бала алып кайту турында хыялланса да, бу нияте тормышка ашмады. Улларының сөйкемле сөякле кызлар алып кайтуларын теләде. Үзе күргән кыерсытуларны ул беркайчан киленнәренә күрсәтмәс иде.

Мең хыяллар белән янып йөргән, бер минутны да бушка уздырмаган, аз гына вакыты булса да, бишкә ярылырдай булып йорт өчен чапкан Илшат кинәт кенә хәлсезлектән зарланып, өенә иртәрәк кайтты. Кайнар чәй эчеп ятып торырга дип, бүлмәсенә кереп китте. Йоклый алмады, әллә нинди шомлы төшләр күрде, саташып бетте.

Салкын тидереп, дәвалана алмыйча вафат булган якын дусты Илдар белән чәчәкле болыннарда йөрде. Аның белән юл фаҗигасенә эләгеп гомере өзелгән Сиринәгә чәчәкләр җыеп бирделәр. Коты алынып, манма суга батып торып утырганын үзе дә сизмәде...

Тормыш мәшәкатенә бирелеп, ыгы-зыгы эчендә кайнап күптән әлеге дусларын исенә алганы булмаган икән инде. “Онытты дип борчылалар бугай. Сәдака бирергә кирәк”, - дип уйлап куйды йокыдан уянган ир. Шулвакыт бүлмәсенә эшкә барырга дип җыенган хатыны килеп керде. Эшләрне кушып, өйрәтеп калдырырга иде исәбе. Ирнең агарган йөзен күреп ул аптырап китте. Кулы белән битләрен, маңгайларын сыпырып алды. Тән кайнарлыгын тоеп, иреннәрен тидереп карады. Аннан градусник алып килде. Бу вакытта Илшатның температурасы булмаса да, кан басымы түбән төшеп киткән иде. Калтырау, хәлсезлек, йокымсырау барысы бергә ирне аяктан еккан.

Ирнең беркайчан да алай авырганын күргәне юк иде Лилиянең. Югалып калды. “Ашыгыч ярдәм”нең номерын исенә төшерә алмады. Фельдшерның номеры телефоныннан бетереп юкка чыккан. Кабаланып күршесен җыйды, аны үзләренә чакырды. Бу вакытта каргышмы, рәнҗешме, бозыммы дип куркуга да калды. Кайнанасы барган саен каргап җибәрә. Лилия җаена торуын күтәрә дә, кичерә дә алмый. Әни теләкләренең кабул булуы да бар дип шомланды. Бер карасаң, гаепсезгә бит, киленне якын итә алмау нәтиҗәсендә.

Әгәр аякка баса алмаса? Шул ятудан күзен ачмаса? Лилия ничек яшәр? Улларын кем тәрбияләр. Гаиләсенә яшәргә ирек бирерләрме. Әле үзе яклап торгач та чак кына бит... Юуук, аңа болай ятарга ярамый. Ул яшәргә тиеш. Ул гаиләсенә кирәк!

Бу ирнең башында бөтерелгән уйлар иде. Артыгын сөйләргә хәле булмады. Хатынына тутырып карады да, барысын да яхшыга юрап, кабат караватка ятты.

Аннан тоник кына фельдшер килгәнне хәтерли. Хатынының сумка җыйганы исендә. Калганнарын бик белми дә. “Ашыгыч ярдәм” машинасында ул аңын җуйган. Уянып киткәндә хатыны янәшәсендә, үзенә система куелган иде.

Ирнең хәле яхшырмады. Бу борчулы көннәр Лилиянең йокысын качырды.

Иренең чын кирәк вакыты. Улының документларын тапшырасы, кешеләрен күреп сөйләшәсе, озак кына кала юлын таптыйсы бар. Икенче улларын бер айга лагерьга җибәрергә уйлаганнар иде. Юлламаны шулай ук барып алырга кирәк. Ир борчуларын хатынга сиздермәгән кебек, Лилия дә артыгын сөйләмәде. Эчтән генә иренә гомер сорады. Парлы яшәүләргә ни җитә. Кырыс замана җилләре икәү каршы торганда гына сизелми.

Илшатның хәлендә бер дә алга китеш булмады. Аннан районнан Казанга алып киттеләр. Якыннарына аңа сәламәтлек сорап Ходайга ялварырга гына калды. Ир яшәү өчен көрәшә башлады. Нилектән авыруын да, каян килеп чыгуын да төгәл аңлатучы булмады. Лилия кала белән район арасында йөрде. Биредә дә утыра алмый, калдырып китәргә дә йөрәге кушмый.

Лилия әле хастаханәгә чапты. Әле улының кәгазьләрен җыйды. Өмет белән килсә дә, бер дә үзгәреш сизмәде.

*(Дәвамы 8 нче биттә)*



podpiska.pochta.ru

(*Дәвамы. Башы 6-7 нче битләрдә*)

# Рәнҗешме, тәкъдирме?

Ирнең кан басымы рәтләнде дигәндә, температурасы күтәрелде. Аннан бөерләрендәге ташлары кузгалып, иргә операция кирәклеге ачыкланды.

Телефонга җавап бирергә дә курка башлады хатын. Начар хәбәр ишетүдән шулай котыла алыр төсле иде. Башындагы уйларны тәртипкә китерәсе урында, фаразлары белән буталып, төшенкелек утында янды.

Ир ягы Илшатның авыруы өчен Лилияне гаепләде. Тормышның бөтен мәшәкатен аның өстенә калдыруда битәрләп, күз яшьләрен түктерделәр. Нинди генә ялалар ишетмәде ул. Кайнанасы килеп, хастаханәдән үк куып чыгарды. Шул төн югалтулар алып килде.

Илшат терелә алмады. Илле яше дә тулмаган килеш китеп барды. Операцияне күтәрә алмады. Аны җирләү дә кеше төсле булмады. Кайнана алар йортына килеп тавыш чыгарды, сәдакаларны да хатынга ышандырмады. Хәтта ашлары да әнисе йортында аерым, гаиләсе калган йортта аерым узды. Туганнар арасында да үпкәләшүләр башланды. Нинди ызгыш чыкса да, гаепле кеше булып Лилия калды.

Югалту белән килешү бик авыр булды хатынга. Менә әле хәзер дә башына төрле уйлар килә. Бәлки, юлында башка хатын очраган булса, Илшат та бу яшендә җир куенына кереп ятмас иде. Әнисе догаларын алып яшәсә, тормышы да уңар, язмышы да башкача язылыр иде.

Юкса, яратышып, аңлашып гаилә корганнар иде. Өч ел аралаштылар. Бер дә үпкәләшмичә туй көненә килеп җиттеләр. Илшат кызга әйбәт булды. Лилия дә шундый хөрмәт белән җавап кайтарды.

Тулай торак бүлмәсе таныштырды аларны. Бер яктан булуларын белгәч, тагын да якынаеп киттеләр. Икесенең дә шәһәрдә төпләнеп калмаска дигән уйлары да бар иде. Районга кайтып төпләнделәр. Яшьлекләрендә каршылыклар, киртәләр очрамады. Тормыш сабырлыкта сынаса да, Лилия гаиләсеннән дә, тормышыннан да канәгать иде.

* * *

Лилиянең яралы күңелен әнә шундый болытлы вакыты. Вакыт дәвалар дигән ышанычы юк. Көннәр узган саен сагынуы арта, җәрәхәтләр зурая бара. Ничек кенә киңәш бирсәң дә файдасы тимәс кебек. Әле янында кечкенә улы бар. Ул да укырга дип калага чыгып китсә, көн-төннәрне ялгыз башы ничек уздырыр.

Әлегә бик тә кыен. Илшат аның уеннан бер минутка да чыгып тормый. Аның белән булган көннәр хәтердә янара. Хатирәләр белән бергә кайнанасының әйткән һәр сүзе, аларга каршы гамәлләре искә төшә. "Бәлки, барып гафу үтенергәдер. Барысын да яңадан башларгадыр", - дигән уйлары да юк түгел. Киләчәген җайга салу өчен барына да риза ул. Киткәннәрне кире кайтару юлы гына юк. Шунысы үзәген өзә.

**Сәйлән ӘХМӘТОВА.**

## Үз-үзеңне кайгыртып...

# Замана чире

Муен остеохондрозы сезгә танышмы?

Соңгы арада күпләр муен тирәсендәге авыртуларга зарлана. Чөнки телефонда күп утырыла, эштә дә компьютердан файдаланабыз. Шуңа күрә муен остеохондрозыннан әлеге рецептны белеп тору зыян итмәс.

Кирәк була: чистартылмаган исле үсемлек мае (нерафинированное масло) һәм вак тоз (кофемолкада вакланган диңгез тозын да кулланырга була).

"Дару"ны тулы бер дәвалану курсы өчен әзерлибез:

10 аш кашыгы вак тоз өстенә 20 аш кашыгы май агызабыз. Яхшылап болгатып, берничә көнгә куеп торабыз. Нәтиҗәдә ак төстәге масса барлыкка килергә тиеш.

Аны һәр көнне муенга сылап, массаж ясыйбыз. Башта ике-өч минут кына, һәр көнне икешәр минут өстәп барып, егерме минутка кадәр арттырасыз.

Массаж ясап бетергәч, муенны дымлы җылы сөлге белән сөртәбез.

Ун процедурадан соң алга китешне сизәрсез. Дәвалану барышында матдәләр алмашы да яхшырачак.

**Искәрмә: табиб белән киңәшләшү зарур!**

## БЕЛГЕЧЛӘР ФИКЕРЕ

# Сериал карау - файдалы!

*Сомнолог, Сеченов университетының йокы медицинасы бүлеге мөдире Михаил Полуэктов йокы алдыннан сериаллар карауның уңай нәтиҗәсе бар, дип белдерде.*

*Белгеч сүзләренчә, табиблар моны файдалы дип саный, чөнки шул рәвешле вакыт үткәрү көндезге эшләрдән арынырга һәм организмны тынычландырырга ярдәм итә.*

*"Сериаллар карау көндезге актив эшчәнлектән арыну варианты булып тора. Һәм организмны тыныч режимга күчерергә булышлык итә", - ди белгеч һәм сомнологлар сериалларны йокларга ятарга бераз вакыт кала карарга киңәш итә, дип тә өсти.*

*Эксперт фикеренчә, кеше шул рәвешле нindидер таныш һәм күңелгә рәхәт халәткә чума, ә бу халәт нерв системасы ял итүгә булыша.*

*Белгеч шуны да ассызыклый: сүз тыныч сериаллар турында бара, кешене нерв киеренкелегенә дучар итә торган фильмнар турында түгел.*

*Ә сез тынычлап йокыга талыр өчен нишлисез, дуслар?*

podpiska.pochta.ru

*Хыянәтне аңлап, йә аклап буламы?*

# Йөрәккә әмер биреп буламы?



Әти белән әнинең тормышлары бик матур иде. Күпләр аларга сокланып карады. Күрше-күләннәр дә, туганнар да безнең гаиләне һәр яктан килгән, үрнәк дип санадылар. Хәтта мин үзем дә, әти әни өчен өзелеп тора, аны гына ярата һәм беркайчан да, берәү белән дә хыянәт итмидер дип уйладым. Ләкин барысы да чәлпәрәмә килде...

Менә көннәрнең берендә әти кайтты да, әнигә: “Мин башка хатынны яратам, ярдәмемнән ташламам”, - дип чыкты да китте. Кабат өйгә килүе рәсми рәвештә аерылышу кәгазьләре белән таныштыру, әнинең ризалыгын алу имзасы өчен булды.

Әтинең китүе аяз көнне яшен суккан кебек иде. Дөрес, ул безне матди яктан тулысынча кайгыртып торды, минем укуым өчен дә үзе генә түләде. Минем белән атнага әллә ничә килеп күрешеп китә иде. Тик өйгә кермәде.

Аерылышуларын әни бик авыр кичерде. Көтмәгән иде ул бу хәлне, шуңа да йөрәгенә якын алды.

Озакламый әтинең яшь хатыны малай тапканын белдек. Әни тагын да ярсып: “Мин бит аңа малай да табып бирә алмадым, шуңа китте ул миннән”, - дип елады. Мин аны ничек тынычландырырга белмичә үзем дә төннәр буе сыктап чыга идем.

Даруларсыз яши алмас булды әни. Нервылары какшап, ахыр чиктә яман чир таптылар анда. Инде хәлләр тагын да мөшкелләнде. Әни түшенкелеккә бирелде, бик нык биреште. Мин кайгыдан үзем дә ярты авыруга әйләндем. Бик кыен чаклар иде ул.

Зар-интизар булып әтигә күңелемне бушатканда, ул миңа гел бер сүзне кабатлады: “Кызым, үзең гашыйк булу, ярату хисен кичермичә, син мине мәңге аңлый алмаячаксың. Әллә мин сезнең газаплануларны күрми, сизми дип беләсеңме? Ялгышасың! Барысын да беләм мин, тик йөрәккә әмер биреп булмый икән”.

Әнигә кирәкле барлык кыйммәтле даруларны да әти сатып алып торды. Ә үзе яшь хатыны һәм баласы белән ялдан-ялга, курорттан-курортка йөрде. Акчасы күп иде аның, дәрәҗәле урында эшләде. Ике гаиләсенә дә житкерде.

Әнине җирләгәндә мин инде укуны тәмамлап, ике ел эшләгән идем. Югалтуны авыр кичерсәм дә, соңга таба әнинең газаплануларын күрү дә бик читен иде.

Күп тә үтмәде әти килеп җитте. Яшь хатыны ун яшьлек улын калдырып китеп барган бит! Тагын да яшьрәкне, баеракны тапкандыр инде. Үз гомеремдә тәүге тапкыр әтинең елаганын күрдем. Үкси-үкси үкенечен белдерде.

Әти улын ялгызы гына тәрбияләп үстерде. Бар көчен аңа мул, җитеш тормыш бирүгә сарыф итте.

Мине дә онытмады, акчасыннан гел өлеш чыгарып торды. Әти күпме генә “энем” белән мине дуслаштырып, аралаштырырга теләсә дә, мин әниемнең рухына хыянәт итмәдем.

Беләм, ул баланың бер генә гаебе дә юк. Тик кабул итү дә читен. Әти шул балага хатыны белән сөенеп утырганда, мин әниемнең чире белән көрәштем. Акчасын бирсә дә, безгә әтинең үзе - игътибары, назы, җылысы, сүзе кирәк иде шул! Бик ялгыштың әти, нык ялгыштың.

Син әйткәнчә, мин дә үсеп җитеп, гашыйк булдым. Балам да бар. Әмма ничек кенә икенче кешегә гашыйк булсам да, күземне тондырып, газиз баламны ташлап, мәхәббәт дип чыгып китмәячәкмен.

Йөрәккә әмер биреп булмый, имеш. Була, әти, була. Синең урында булсам, үзем өчен өзелеп торган хатыным, кызчыгым хакына мин йөрәккә дә әмер биргән булыр идем һәм шул чакта гына олыгайган көнемне үкенечле уздырмас идем.

**Исемем редакция өчен генә.**

podpiska.pochta.ru

## Гыйбрәт

Күптән түгел генә иптәш хатын сөйләгәннәрне газетага да язарга булдым әле. Шуны укыганнан соң күпләр уйга калыр...

Шул иптәш хатынның дустының танышы белән булган хәл бу. Исемен шартлы рәвештә Нина дип алыйк. Кырык яшь булса да, зифа буйлы, мөлаем йөзле әле. Егерме дүрт яшендә үк иреннән тол калган, инде баласы да башлыкүзле икән.

Ялгызлыктан туйган ханым, картлыгында ышанычлы терәк булыр дип, ир-ат эзләү хәстәренә керешкән. Танышу сайтларында тормыш корып, бергәләп яшәргә теләүче ирләр шактый була. Хыялындагы кеше булып тоела аңа Роберт. Гаиләсе юк, өйләнсә дә аерылышкан, балалары булмаган. Үзенә кырык алты яшь икән. Робертның кыяфәте - төсе-бите, килеш-килбәте дә ошаган Нинага.

# Мине кусаң, тынычлап яшәрмен димә!



Гади генә урында эшләсә дә, акчасы да була аның. Шәһәр җирендә бурычсыз-нисез генә фатир алу читен бит!

Интернет аша хәбәрләшеп торгач, очрашалар болар. Күрешеп азрак сөйләшүгә үк ялгызлыктан тәмам алҗыган Нина Робертка гашыйк булып та куя. Ир дә аны ошатты дип уйлый.

Шуннан соң алар көн саен күрешәләр. Яшь җилкәнчекләр кебек мәхәббәт уйныйлар. Кайчакларда ир Нинада куна да калгалый. Итагатьле, игътибарлы, аракы эчми торган ир белән танышуына сөенеп туя алмый Нина. Тагын да яшәреп, матурланып китә.

Шуннан соң Робертны үзенә күченергә чакыра. "Синнән башка яши алмас булдым", - дип хыяллана хатын.

Тик бераздан идеаль ир дип санаган Роберты кичләрен өйгә салгалап кайта башлый. Сумка тотырып сырасын ташый. Нинаның төннәре исерек ирне саклап уза, сүгенү сүзләреннән колаклары тона.

Роберт Нинага авыз ачып сүз әйтергә дә ирек бирми. Артыграк сүз ычкындырса, шунда ук йодрыклар ярдәмендә "тәрбияли" аны Роберт. Зәңгәрләнгән күзләр, шешенгән бит белән эшкә барып күп тапкырлар оят утында янган ул. Хурлыгы ни тора бит. Йортка керткән килмешәк кыйнап торсын инде. Куып та чыгара алмый Робертны, тегесе куркыта: "Әгәр мине кусаң, тынычлап яшәрмен димә!" - ди.

Беркөнне кич шулай кыйнап ташлагач, ханым бу хәшәрәттән котылырга ниятли. Тегесе чәчәк бәйләме белән торт күтәреп кайтып гафу үтенгәч, мескенкәй аны янадан кичерә... Шундый кичерүләр берничә тапкыр кабатланганнан соң, Нина ныклы карарга килә. Куам, беттекитте. Ә Роберт артык сүзләр әйтеп тормыйча гына чыгып китә.

Икенче көнне эштә вакытта Нинаның кесә телефонына смс хәбәр килә. "Әгәр дә миңа кире кайт димәсән, фатирыңа ут төртәм. Син белми дә калырсын! Бөтен күршеләрең дә янар, гомереңнең азагына кадәр аларга бурыч түләп тилмерерсең".

Шуннан соң Нина Робертны кире кабул итәргә мәҗбүр була. Шул көннән бирле газапланып яши ул исерек ир белән.

"Ялгыз башым, тыныч колагым булган икән. Никләр генә танышасы иттем", - дип үкенеп туя алмый хатын.

Кайчакларда ялгызлыкның да, ирекнең дә үз кадере була шул.

**Л. ЯКУПОВА.**

podpiska.pochta.ru